РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

___05.04.2019______ № 335-п

Шәһәр төзелеше өлкәсендә муниципаль
хезмәтләр күрсәтүнең аерым административ
регламентларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 февралендәге 436-р номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасында «Төзелешкә һәм территориаль планлаштыруга рөхсәт алу» максатчан моделен гамәлгә кертү буенча чаралар планының (юл картасы) 2.1.1 пунктындагы 2.1. бүлекчәсенең 2 бүлеге һәм 2.4.1 пунктының 2.4 бүлегенә туры китерү максатларында Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР ЧЫГАРА:

**1.** Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының “Шәһәр төзелеше өлкәсендә муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында” 2018 елның 19 декабрендәге 1844-п номерлы карары белән расланган төзелешкә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә::

**1.1.** Административ регламентның 2.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«

| | | |
|---|---|---|
| 2.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып, туктатылу мөмкинлеге Россия Федерациясе законнары белән каралган очракта муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору срогы | Төзелешкә рөхсәт бирү-гариза бирү көнен дә кертеп, биш көн[1].<br>Төзелешкә рөхсәт бирү вакытын озайту-биш көн.<br>Төзелешкә рөхсәт бирүгә үзгәрешләр кертү-биш көн.<br>Төзелешкә рөхсәт дубликатын бирү-өч көн.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган | РФ Шәһәр төзелеше Кодексының 51 маддәсенең 11, 21.14 бүлекләре |

»

**2.** Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты 2018 елның 19 декабрендәге 1844-п номерлы “Шәһәр төзелеше өлкәсендә муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында” карары белән расланган җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын әзерләү һәм бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

**2.1.** Административ регламентның 2.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

[1] Муниципаль хезмәт күрсәтүнең вакыты административ процедураларны гамәлгә ашыру өчен минималь кирәкле суммар вакыттан чыгып билгеләнгән. Административ процедураларның озынлыгы эш көннәрендә исәпләнә.

«

| | | |
|---|---|---|
| 2.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып, туктатылу мөмкинлеге Россия Федерациясе законнары белән каралган очракта муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору срогы | Гариза теркәлгәннән соң 14 көн эчендә [2]<br>Җир кишәрлегенең элегрәк расланган шәһәр төзелеше планы дубликатын бирү гариза кергән вакыттан алып 4 көн эчендә гамәлгә ашырыла, әмма 10 календарь көннән дә артык түгел.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган | РФ Шәһәр төзелеше Кодексының 57.3 маддәсенең 6 бүлеге |

»

**3.** Әлеге карарны информацион-телекоммуникацион “Интернет» челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресындагы Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм http://saby.tatarstan.ru адресындагы Саба муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга

Саба муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе М.Р. Ишниязов